# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ятмас Дусай авыл җирлеге Ямбулат-Пустошь авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**24 ноябрь, 2025 ел** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2026 елда Кукмара муниципаль районының Ятмас Дусай авыл җирлеге Ямбулат-Пустошь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 1 төркем инвалидларыннан; 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 5000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урам яктырту;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- коеларны төзекләндерү, ремонтлау өәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;

-һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре)булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт чикләрендә җәяүлеләр күперләрен һәм юл уткәргечләрен , гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен җир өсте күперләрен ремонтлау;

- каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

-ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ятмас Дусай авыл җирлеге башлыгы Ә.И. Шәймәрданова